**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 31 маендагы 2265 номерлы карары

# Казан шәһәре Идел буе районының Җиңү проспектындагы җир кишәрлекләрендә ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарга 1 номерлы, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

1.1.1. йогынты ясала торган мәйдан – 537 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары 16:50:150303:64, 16:50:150303:56, 16:50:150303:19;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Җиңү проспекты;
- билгеләүнең максаты: алга таба файдалану өчен «Кадастр номеры 16:50:150303:2387 булган җир кишәрлеге чигенә кадәр газүткәргечнең тармаклануы» газ белән тәэмин итү объектын төзү;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлары нигезендә билгеләнә дип гамәлгә кертергә.

3. Әлеге карарның 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт 3 айны тәшкил итә дип билгеләргә.

4. «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1 номерлы, 2 номерлы кушымталар нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

5. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалану өчен материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталын-

да (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. кадастр номерлары 16:50:150303:64, 16:50:150303:56, 16:50:150303:19 булган җир кишәрлекләренең хокук хуҗалары белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;


7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 31 маендагы
2265 номерлы карары белән расланды

**16:50:150303:19, 16:50:150303:56, 16:50:150303:64**
**кадастр номерлы җир кишәрлекләренең бер өлешенә**
**ачык сервитут йогынтысы чикләре**




| Масштаб 1:1000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | яңа барлыкка килгән характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:150303 | кадастр кварталы |
| 16:50:150303:19, 16:50:150303:56, 16:50:150303:64 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |